ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2020 елның 6 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 58**

2020 елга граждан керемenең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49,51 статьяларына таянып, « “Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2007 елның 13 июлендәге 31 номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм әлеге законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү методикасы нигезендә, Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык Министрлыгы 2018 елның 19 декабрендәге 822 номерлы “2020 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының бер квадрат метр гомуми мәйданының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында” Россия Федерациясе Торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының Боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 749 792 сум;

1.1.2. ике кешелек гаилә өчен – 2 227 008 сум;
1.1.3. өч кешелек гаилә өчен - 2 863 296 сум;

1.1.4. дүрт кешелек гаилә өчен – 3 817 728 сум;
1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 4 772 160 сум;
1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 5 726 592 сум;
1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 6 681 024 сум.

1.2. һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 19032,72 сум;

1.2.2. ике кешелек гаилә өчен – 12111,73 сум;

1.2.3. өч кешелек һәм аннан да күбрәк кеше өчен – 10381,48 сум.

2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

3. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыруны тәэмин итәргә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырырга (http://chistopol.tatar.ru/).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитеты
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов